Татарстан Республикасы

Яшел Үзән муниципаль районы

"Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы 5 нче гимназиясе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе"

Сыйныф сәгате: Якташыбыз-Равил Гарәфетдин улы Сәйфетдинов

"Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы 5 нче гимназиясе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе" технология укытучысы Абзалина Лилия Рафисовна

2022 нче ел

**Тема:** Якташыбыз-Равил Гарәфетдин улы Сәйфетдинов.

**Максат:**

1. Укучыларны якташыбыз Равил Гарафетдин улы Сәйфетдинов торшыш юлы белән таныштыру.
2. Укучыларны Равил Гарафетдин улы шигырьләре үрнәгендә : туган якка һәм телгә мәхәббәт, милли рух сеңдерү, милли тәрбия бирү, әти- әниләргә, халыкка хөрмәт хисләрен тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Равил Гарафетдин улы Сәйфетдинов портреты, китап күргәзмәсе, презентация, интерактив такта.

**Сыйныф сәгате барышы.**

Укытучы. (1 слайд)Исәнмесез, укучылар! Без бүген Равил Гарафетдин улы Сәйфетдинов иҗатын һәм тормыш юлына багышланган сыйныф сәгатенә җыелдык. Класс сәгатен башлар алдыннан берберегезне матур итеп сәламлик.

Укытучы:(Талгын көй уйный.) (2 слайд)

Яшел Үзән районы – танылган шәхесләргә бай. Атаклы язучылар да, төрле фән өлкәләрендә эшләгән галимнәр, шагыйрьләр аз чыкмаган Яшел Үзәгн районыннан. Безнең бөек мәгърифәтчебез Каюм Насыйри һәм талантлы рәссам Константин Васильев, беренче татар әлифбасына нигез салучы Шакирҗан Таһири да бу яклардан. Габдулла Тукайның апасы соңгы көннәрен Васюково авылында яшәгән, шунда вафат булган.

(3 слайд) Равил Гарафетдин улы Сәйфетдинов безнең якташыбыз. Равил Гарәфетдин улы 1938 нче елның 14 нче октябрендә Яшел Үзән районының Мулла Иле авылында туа. Әтисе Гарәфетдин ике бертуганы Хәйретдин, Җамалетдин белән сугышта һәлак булганнар. Әнисе Бигинур көн-төн колхозда эшләгән. Өч баласын сугыш кыры узенә аганга тузә алмыйча елаган Фатыйма ананың ике күзе сукырайган. (4 слайд)

Укытучы: Укучылар Равил Гарафетдин улы Сәйфетдиновның “Гомер буе мин әтине эзлим” дигән шигыреннән өзек тыңлап китик. (Бер укучы шигырь сөйли).

**1нче укучы.** Әти, әти! Сине хыялымда
Шундый җанлы итеп тергездем:
Син – комсомол секретаре менә,
Ныгытасың колхоз нигезен.
Ашлык амбарында мөдир булып.
Һәр бөртекнең белеп кыйммәтен.
Герләр түгел, намусың белән үлчәп,
Саклыйсың син халык икмәген.
Син гомергә минем белән бергә
Яшисең ич, әти, янәшә.
Киңәшләшәм, бәхәсләшәм, әти,
Синең белән бергә сөйләшәм.
Без тормышның олы сукмагыннан
Зур максатлар куеп атлыйбыз.

Безне беркем юлдан саташтырмас
Чыкмас безнең яман атыбыз.
Һәр таң саен, әти, минем белән
Каршылыйсың хезмәт иртәсен.
Син мәктәпкә барып минем белән
Балаларга дәрес бирәсең.
Безнең эшебез, әти, бик җаваплы.
Күпне сорый бездән киләчәк.
Безнең йөрәк килер буыннарның
Күкрәгендә әле тибәчәк. (1981 ел)

Укытучы: (5 слайд). Урта мәктәпне бетергәч, 1956 елда Казан университетының татар теле Университет студенты һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергән. Равил Сәйфетдиновның 1958 нче елда басылып чыккан “Далада туган хисләр” дигән шигырьләр циклы бар. Тырыш хезмәте өчен Равил Сәйфетдинов биредә “Чирәм җирләрне үзләштергәне өчен” дигән медаль белән бүләкләнгән. (Берничә укучы шигырь сөйли).(6 слайд)

**2нче укучы.**
Дала юлында
Дулкынлана зәңгәр күк астында
Алтын агым - бодай диңгезе;
Әнә совхоз – тиздән карталарда
Яктырачак шәһәр нигезе.
Чирәм җирләр!
Чорыбызга тиң сез,
Нинди киң сез, Нинди матурлар!
Кабатлыйлар йөрәк тибешемне
Сезнең кырлардагы моторлар. (1958 ел)
**3 нче укучы.**
Чирәм җирләрдә
Төн. Салават күперләре агыла,
Моннан гаҗәп тагын нәрсә бар?
Монда сөрелеп килгән чечен карты
Серне ачты: “Атом сыныйлар”.(1957 ел)
**4 нче укучы.**
Яшьлек җырлый
Яшьлек җырлый.
Яшьлек көчен сыный,
Ямьгә төреп дала күкрәген;
Яраттым мин бөтен җаным белән
Бу җирләрдә тормыш күкрәвен.
Буыннарым меңгә бөгелсә дә,
Арып-талу, йончу белмәдем;
Бу җирләрдә рухым корычланды,
Бодай төсен алды беләгем.

“Котырып” бодай уңган далаларда
Бөреләнә татлы уйларым;
Эш өстендә туган җырым белән
Яңгыратам Иртыш буйларын! (1958ел)

Укытучы: (7 слайд) 1963-2007 нче елларда Мулла Иле урта мәктәбендә кырык биш ел буе бертөзлексез хезмәт иткән. Татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, немец теле, гарәп теле, дин тарихы предметларын укыткан. 1968-1970 нче елларда – завуч, 1971- 2000 нче елларда мәктәп директоры булган. Равил Сәйфетдиновнең хезмәте бәяләнмичә калмый. Аңа “Россиянең мәгариф отличнигы”, “Татарстанның атказанган укытучысы” исемнәре, “СССР Мәгариф министрлыгының Мактау Грамотасы”, “Хезмәт ветераны” медале бирелә. (8 слайд)

Равил Сәйфетдинов яңа шигырьләр иҗат итә, әдәби эшчәнлеген туктатмый.

(Укучылар шигырь сөйлиләр)

**5 нче укучы.**

Татар мәктәбе
Мәктәп – гүя киләчәккә карап
Сәфәр чыккан заман корабы.
Шул корабта, ил өметен аклап,
Бертуктаусыз юлда барамын.
Давыллар да була, томаннар да,
Зәңгәр күкне каплый болытлар.
Ләкин кояш чыга, хуплап безне,
Еракларга чакыра офыклар.
Көннәребез булсын гел кояшлы,
Төннәребез – айлы, йолдызлы.
Шулай булсын өчен мәгърур мәктәп
Сөеп бага һәрбер ул-кызны.
Рәхмәт, мәктәп, нурлы гыйлем йорты –
Балачакның алтын сарае!

**6 нчы укучы.** Уйнатасың назлап һәм кадерләп
Халкыбызның милли сорнаен.
Яшь гакылга гыйлем сеңдерәсең
Тормыш күкләренә үрләргә;
Яшь күңелгә ак нур иңдерәсең,
Өйрәтәсең чынлап сөяргә.
Синдә үсә илнең киләчәге –
Әткәй-әнкәйләрнең дәвамы –
Кешеләргә изгелекләр кылып,
Явызлыкны җиңә торганы.
Халкыбызның күз карашы, мәктәп,
Өмет белән сиңа төбәлгән.
Син бар чакта бәхет һәм тынычлык

Булыр, дибез, килер көннәргә. (2000 ел)

Укытучы: (9 слайд) Равил хәзрәт Сәйфетдин 2005 нче елдан алып Мулла Иле мәчете имамхатыйбы вазифаларын башкарган. 2017 нче елда рухи-әхлакый традицияләрне үстерүдә, тынычлык һәм конфессия ара килешүне ныгытуда зур көч куйганы өчен Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнә. 2018 нче елның 10 нчы февралендә вафат.

**7 нче укучы.**

Татар теле
Латин теле кебек үле түгел
Татар теле.
Рецептларда түгел, көнкүрештә
Яши тере.
Урыс теле кебек бөек түгел
Татар теле.
Бөек телләр үлгәндә дә ләкин
Бетмәс түлке. (1996 ел)

**Йомгаклау.**

Равил абый Сәйфетдинов шигырьләре туган якка һәм телгә мәхәббәт, милли рух һәм тәрбия бирә, әти- әниләргә, халыкка хөрмәт хисләрен тәрбияли. Ул язган шигырьләр һәрвакыт халык күңелендә сакланыр.

(10 слайд) Сыйныф сәгатебез тәмам. Игътибарыгыз һәм катнашуыгыз өчен рәхмәт.